КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 сентябрь г.Казань № 1033

Хосусыйлаштырылган электр челтәре хуҗалыгы объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына карата эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 301 статьясы, «Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Хосусыйлаштырылган электр челтәре хуҗалыгы объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына карата эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 сентябрь, 1033 нче
карары белән расланды

Хосусыйлаштырылган электр челтәре хуҗалыгы объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына карата эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Бу Тәртип «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 178-ФЗ номерлы Федераль закон) $30^1$ статьясындагы 11 пункты, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $7^1$ пункты нигезендә эшләнде һәм хосусыйлаштырылган электр челтәре хуҗалыгы объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына карата эксплуатация йөкләмәләре (алга таба – объект, эксплуатация йөкләмәләре) шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруны регламентлаштыра.

2. Хосусыйлаштырылган объектларга карата эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары (алга таба – вәкаләтле орган):

электр челтәре хуҗалыгы объектларына һәм җылылык челтәрләре, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары һәм мондый системаларның аерым объектлары белән үзара бәйләнештәге электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшкәртү чыганакларына карата – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;

җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм шундый системаларның аерым объектларына карата (җылылык челтәрләре, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары һәм мондый системаларның аерым объектлары белән үзара бәйләнештәге электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшкәртү чыганакларыннан башка) – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы.

3. Хосусыйлаштырылган объектларның милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасы тарафыннан эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тоту күчмә һәм документар тикшерүләр рәвешендә планнан тыш тикшерүләр (алга таба – тикшерү) үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Күчмә тикшерү хосусыйлаштырылган объектларның урнашу урыны буенча гамәлгә ашырыла.

Документар тикшерү вәкаләтле органның урнашкан урынында уздырыла.

4. Вәкаләтле органның вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) мотивлаштырылган язма рәсми сораулар нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

б) хезмәт таныклыгын һәм вәкаләтле орган җитәкчесенең тикшерү билгеләнү турында боерыгы күчермәсен күрсәтеп, территориядә һәм аларда урнашкан электр челтәре хуҗалыгы объектларында, җылылык энергиясе чыганакларында, җылылык челтәрләрендә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларында һәм мондый системаларның кайбер объектларында тоткарлыксыз булырга.

5. Вәкаләтле органның вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләргә бурычлы:

а) Россия Федерациясе законнарын, тикшерү үткәрелә торган объектның милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

б) вәкаләтле орган җитәкчесенең тикшерү билгеләнү турындагы боерыгына таянып, аны билгеләү нигезендә тикшерү үткәрергә;

в) тикшерүне – хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына, күчмә тикшерүне хезмәт таныклыкларын, вәкаләтле орган җитәкчесе боерыгы күчермәләрен күрсәткәндә генә үткәрергә;

г) тикшерү үткәрелгән вакытта объект милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасының җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә объектта булырга каршылык күрсәтмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

д) объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының тикшерү үткәргәндә булган җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны күрсәтергә;

е) объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

ж) бу Тәртипнең 12 пунктында каралган тикшерү үткәрү срогын үтәргә.

6. 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^1$ статьясындагы 6 пункты нигезендә объектка карата эксплуатация йөкләмәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

кулланучыларны һәм абонентларны тиешле товарлар белән тәэмин итү, аларга хезмәтләр күрсәтүне туктатуның максималь чорын (әлеге чорны озайтып җибәрү объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының эксплуатация йөкләмәләрен шактый бозу булып тора);

тиешле товар белән тәэмин ителмәүнең, хезмәтләр күрсәтелмәүнең рәхсәт ителгән күләмен (әлеге күләмне арттырып җибәрү объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының эксплуатация йөкләмәләрен шактый бозу булып тора).

7. 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^1$ статьясындагы 3 пункты нигезендә объектка карата эксплуатация йөкләмәләренең шарты: кулланучыларга һәм абонентларга Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) буенча товарлар кайтарту, хезмәтләр күрсәтү,

кулланучыларның һәм абонентларның тиешле товарлар алу, аларга хезмәт күрсәтелү мөмкинлеген тәэмин итү (кулланучыларга товарлар бирүне, хезмәтләр күрсәтүне туктату яисә туктатып тору Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган очраклардан тыш).

8. 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30[1] статьясындагы 8 пункты нигезендә рәсмиләштерелгән эксплуатация йөкләмәләренең шартлары Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар составына һәм җитди шартлар буларак түбәндәгеләргә кертелергә тиеш:

а) әгәр электр челтәре хуҗалыгы объектлары, җылылык энергиясе чыганаклары, җылылык челтәрләре, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары һәм мондый системаларның аерым объектлары сату юлы белән хосусыйлаштырылса, әлеге объектларны һәм (яисә) системаларны сатып алу-сату шартнамәсенә (алга таба – объектны сатып алу-сату шартнамәсе);

б) әгәр электр челтәре хуҗалыгы объектлары, җылылык энергиясе чыганаклары, җылылык челтәрләре, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары һәм мондый системаларның аерым объектлары аларны акционерлык җәмгыятенең устав капиталына кертем буларак кертү юлы белән хосусыйлаштырылса, акцияләрне сатып алу-сату шартнамәсенә (алмашу шартнамәсенә).

9. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы милек хокукын дәүләт теркәвенә алган көннән 10 эш көне эчендә вәкаләтле органга объектны сатып алу-сату шартнамәсе һәм (яисә) акцияләрне сатып алу-сату шартнамәсе (алмашу шартнамәсе) күчермәләрен җибәрә.

10. Тикшерүләр үткәрү өчен вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен контрольдә тоту комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзү һәм аның составын раслау турында боерык чыгарыла.

11. Тикшерү предметы – объектның милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасы тарафыннан эксплуатация йөкләмәләре шартлары үтәлү.

12. Тикшерүләр вәкаләтле орган җитәкчесенең боерыгы (алга таба – тикшерү үткәрү турында боерык) нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерү үткәргәндә тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсе боерык алыну фактын теркәргә мөмкинлек бирә торган теләсә нинди ысул белән тикшерү үткәрелә башлаганга кадәр кимендә 24 сәгать кала объектның милекчесенә һәм (яисә) законлы хуҗасына җибәрелә (бирелә).

Тикшерүләр объектның милекчесенә һәм (яисә) законлы хуҗасына тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе җибәрелгән (бирелгән) көннән иң күбе 10 эш көне алып барыла.

13. Планнан тыш тикшерүләр вәкаләтле органга гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан эксплуатация йөкләмәләре бозылу фактлары турында мәгълүмат кергән очракта үткәрелә.

14. Тикшерү нәтиҗәләре объект милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасы тарафыннан эксплуатация йөкләмәләренең шартлары үтәлү (үтәлмәү) турындагы акт (алга таба – тикшерү акты) белән рәсмиләштерелә.

15. Тикшерү акты вәкаләтле органның тикшерү үткәрүдә катнашучы вазыйфаи

заты тарафыннан тикшерү тәмамланган көннән 10 эш көненнән дә артмаган срокта ике нөсхәдә төзелә, анда түбәндәге белешмә мәгълүмат күрсәтелә:

тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

тикшерү үткәрү турындагы боерыкның датасы һәм номеры;

Комиссиянең тикшерү үткәргән әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы – булганда) һәм вазыйфалары;

тикшерү үткәрелгән объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының исеме һәм урнашу урыны;

эксплуатация йөкләмәләре шартлары;

тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау датасы;

тикшерү үткәргәндә билгеләнгән хәлләр һәм Комиссиянең тикшерү үткәргән әгъзаларының нигезле нәтиҗәләре;

объектның милекче һәм (яисә) законлы хуҗасы тарафыннан эксплуатация йөкләмәләре шартларын үтәү (үтәмәү) турында мәгълүмат;

объект милекчесенең һәм (яисә) законлы хуҗасының тикшерү акты белән танышу йә танышудан баш тарту турында мәгълүмат.

Тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләренә бәйле документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

16. Тикшерү акты Комиссиянең тикшерү уздырган барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм төзелгән көненнән өч эш көне эчендә вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан раслана.

Тикшерү нәтиҗәләренә бәйле документларның күчермәләре белән бергә тикшерү актының бер нөсхәсе расланган көненнән өч эш көне эчендә объектның милекчесенә һәм (яисә) законлы хуҗасына тикшерү акты белән танышу турында йә танышудан баш тарту турында имза куеп тапшырыла, икенче нөсхәсе вәкаләтле органда саклана.

Тикшерү актының күчермәсе Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына расланган көненнән өч эш көне эчендә җибәрелә.

Объектның милекчесе һәм (яисә) законлы хуҗасы тарафыннан тикшерү акты белән танышудан баш тартылган очракта, мондый тикшерү акты тапшыру турындагы хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, әлеге хәбәрнамә вәкаләтле органда саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.